МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.04.2021 г. Казань № 765

Татарстан Республикасында балаларга өйдә үпкәгә озакка сузылган ясалма вентиляция ясауны оештыру турында

Татарстан Республикасында балаларга паллиатив медицина ярдәмен үстерү максатларында, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 31 маендагы «Сәламәтлек саклау өлкәсендә үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы медицина оешмалары, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары һәм иҗтимагый берләшмәләр, башка коммерцияле булмаган оешмалар арасында үзара хезмәттәшлек тәртибен дә кертеп, паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 345н/372н номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, «Кеше организмы органнары һәм системалары функцияләрен саклап калу өчен билгеләнгән медицина эшләнмәләрен паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә өйдә файдалану өчен медицина оешмасыннан пациентка (аның законлы вәкиленә) тапшыру Тәртибен раслау турында медицина оешмасыннан тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2019 елның 10 июлендәге 505н номерлы боерыклары белән, боерам:

1. Расларга:

Амбулатор шартларда (өйдә) балаларга махсус медицина җиһазларын (комплектта респиратор блогы, тоткычлы контур һәм дымландыргыч, сумка (транспортлау өчен тартма (укладка), кислород чыганагы белән тоташтыру өчен шланг), медицина кислород концентраторы, йөткерттерү аппараты, вакуумлы электроаспираторы, пульс оксиметры, чиләнүгә каршы матрас булган үпкәләрне ясалма вентиляцияләү аппараты) һәм аңа кирәкле чыгым материаллары кулланып, паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыруны гамәлгә ашыручы медицина оешмалары исемлеген (әлеге боерыкка кушымта №1 нигезендә);

Өйдә үпкәгә балаларга озакка сузылган ясалма вентиляция ясау чараларын оештыру тәртибен (алга таба — тәртип) (әлеге боерыкка кушымта №2 нигезендә);

Медицина җиһазларын өйдә түләүсез вакытлы файдалануга тапшыру турында килешүнең (алга таба – килешү) тәкъдим ителгән формасын (әлеге боерыкка кушымта №3 нигезендә).

2. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыруда катнашучы беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче медицина оешмалары җитәкчеләренә оештыруны тәэмин итәргә:

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 31 маендагы «Сәламәтлек саклау өлкәсендә үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы медицина оешмалары, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары һәм иҗтимагый берләшмәләр, башка коммерцияле булмаган оешмалар арасында үзара хезмәттәшлек тәртибен дә кертеп, паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 345н/372н номерлы боерыгы нигезендә, амбулатор шартларда (өйдә) балаларга махсус медицина җиһазларын кулланып (комплектта респиратор блогы, тоткычлы контур һәм дымландыргыч, сумка (транспортлау өчен тартма (укладка), кислород чыганагы белән тоташтыру өчен шланг), медицина кислород концентраторы, йөткерттерү аппараты, вакуумлы электроаспираторы, пульс оксиметры, чиләнүгә каршы матрас булган үпкәләрне ясалма вентиляцияләү аппараты) (алга таба – медицина җиһазлары) паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне;

«Кеше организмы органнары һәм системалары функцияләрен саклап калу өчен билгеләнгән медицина эшләнмәләрен паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә өйдә файдалану өчен медицина оешмасыннан пациентка (аның законлы вәкиленә) тапшыру Тәртибен раслау турында медицина оешмасыннан тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2019 елның 10 июлендәге 505н номерлы боерык һәм әлеге боерык белән расланган тәртип нигезендә пациентка (аның законлы вәкиленә) махсус медицина җиһазларын һәм аңа кирәк булган чыгым материалларын тапшыруны;

балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештырганда ведомство карамагындагы медицина оешмалары табибларының башка медицина оешмалары белгечләре белән үзара хезмәттәшлеген.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының балаларга паллиатив ярдәм күрсәтү буенча баш штаттан тыш белгеченә (С. С. Можгина) балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче медицина оешмалары табибларына оештыру-методик ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасында балаларга өйдә үпкәгә озакка сузылган ясалма вентиляция ясауны оештыру турында» 2009 елның 21 мартындагы 560 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип санарга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары А.Р. Абашевка йөкләргә.

Министр М.Н.Садыйков

22.04.2021 № 765
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгына
Кушымта №1

Амбулатор шартларда (өйдә) балаларга махсус медицина җиһазларын (комплектта респиратор блогы, тоткычлы контур һәм дымландыргыч, сумка (транспортлау өчен тартма (укладка), кислород чыганагы белән тоташтыру өчен шланг), медицина кислород концентраторы, йөткерттерү аппараты, вакуумлы электроаспираторы, пульс оксиметры, чиләнүгә каршы матрас булган үпкәләрне ясалма вентиляцияләү аппараты) һәм аңа кирәкле чыгым материаллары кулланып, паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыруны гамәлгә ашыручы медицина оешмалары исемлеге

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар Республика клиник хастаханәсе» ДАССУ, (Казан шәһ.);

«Кама балалар медицина үзәге» ДАССУ (Яр Чаллы шәһ.);

«Перинаталь үзәкле Балалар шәһәр хастаханәсе» ДАССУ (Түбән Кама шәһ.);

«Лениногорск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ(балалар стационары).

22.04.2021 № 765
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгына
Кушымта №2

Өйдә үпкәгә балаларга озакка сузылган ясалма вентиляция ясау чараларын оештыру тәртибе

1. Әлеге тәртип өй шартларында балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә үпкәләрне озак вакытлы ясалма вентиляцияләүне (алга таба - ИВЛ) оештыру чараларын үткәрү кагыйдәләрен билгели.

2. Пациентка (аның законлы вәкиленә) йорт шартларында озакка сузылган ИВЛ үткәрү өчен кирәкле медицина эшләнмәләрен һәм җиһазларын тапшыру турында карар пациент амбулатор шартларда паллиатив медицина ярдәме ала торган медицина оешмасының табиблык комиссиясе тарафыннан 2019 елның 10 июлендәге № 505н Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгы (алга таба - 2019 елның 10 июлендәге № 505н РФ ССМ боерыгы) белән расланган Паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә өйдә файдалану өчен, кеше организмы органнары һәм системалары функцияләрен саклау өчен билгеләнгән медицина эшләнмәләрен медицина оешмасыннан пациентка (аның законлы вәкиленә) тапшыру Тәртибе нигезендә кабул ителә.

Табиблык комиссиясе карары пациентның медицина документациясе кертелә торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

3. Өйдә ИВЛ үткәрүгә хәзерләү өчен пациентны паллиатив ярдәм бүлегенә (паллиатив медицина ярдәме койкасына) госпитализацияләү (күчерү) түбәндәгеләр булганда гамәлгә ашырыла:

өйдә ИВЛ үткәрүгә хәзерләүне гамәлгә ашыручы медицина оешмасының өй шартларында пациентка ИВЛ үткәрүгә күрсәтмәләрнең һәм каршы күрсәтмәләрнең булуын ачыклау турында табиблык комиссиясе карарлары;

өйдә үпкәләрнең ясалма вентиляциясен үткәрүгә пациентның (законлы вәкилнең) кушып бирелә торган форма буенча хәбәр ителгән ирекле ризалыгы (әлеге Тәртипкә кушымта № 1);

әгәр гражданинның хәле үз ихтыярын белдерергә мөмкинлек бирә алмаса яисә законлы вәкилләре булмаса, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге № 323-ФЗ Федераль законына нигезендә табиблар консилиумының карарлары;

ашыгыч хәлләр очрагында медицина оешмаларының ирешерлеге (тәүлек буе эшли торган телефон элемтәсе, килү вакыты 20 минуттан да артмаска тиеш);

пациентның өй шартларының торышы турында анкеталар (тәкъдим ителә торган үрнәк 2019 елның 10 июлендәге № 505н РФ ССМ боерыгы белән расланган, әлеге Тәртипкә кушымта № 2).

Әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән карар кабул итү өчен табиблык комиссиясе составы «Медицина оешмасының табиблык комиссиясен төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау турында» 2012 елның 5 маендагы № 502н Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының боерыгы нигезендә төзелә һәм шул исәптән дәвалаучы табиб, табиб-анестезиолог-реаниматолог, паллиатив медицина ярдәме табибын үз эченә ала.

4. Медицина оешмасында өйдә ИВЛ үткәрүгә хәзерләнүне гамәлгә ашыручы табиб-анестезиолог-реаниматолог:

медицина оешмасының җитәкчесе тарафыннан расланган укыту планына туры китереп, ИВЛда булучы пациентны карау принципларына турыдан-туры карый торган затларның укытуын уздыра; укыту тәмамлангач, ИВЛда булучы пациентны карауны турыдан-туры гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан үзләштерелгән компетенцияләр исемлегенә имза куела, кушып бирелә торган форма буенча (әлеге Тәртипкә кушымта № 3).

пациентка өйдә ИВЛ үткәрү өчен медицина эшләнмәләрен, җиһазларын һәм ИВЛ параметрларын сайлауны гамәлгә ашыра).

5. Өйдә ИВЛ үткәрү өчен стационардан чыгару өчен мәҗбүри шартлар:

өй шартларында озакка сузылган ИВЛ үткәрү өчен кирәкле медицина эшләнмәләре һәм җиһазлары булу;

пациентны карауны үтәүче затның, әлеге Тәртип нигезендә, ИВЛда булучы затны карау принципларына укытуны узуы;

пациентның тотрыклы хәле;

өйдә озакка сузылган ИВЛда булган пациент яши торган территориягә хезмәт күрсәтүче медицина оешмасында, редукторлы кислород баллоны, генератор, респиратор интерфейслар белән өстәмә җиһазландырылган балаларга паллиатив медицина ярдәменең күчмә патронаж хезмәте булу;

пациент амбулатор шартларда паллиатив медицина ярдәме ала торган медицина оешмасының табиблык комиссиясенең пациентка (аның законлы вәкиленә) өй шартларында озакка сузылган ИВЛ үткәрү өчен кирәкле медицина эшләнмәләрен һәм җиһазларын тапшыру турында карары.

Стационар шартларда паллиатив махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасыннан пациентны чыгарганда стационар авыруның медицина картасыннан өземтә бирелә, анда алга таба күзәтү, дәвалау буенча, шул исәптән амбулатор шартларда (өйдә) респиратор ярдәмен һәм карауны оештыру буенча киңәшләр күрсәтелә.

Өземтә пациентның яшәү урыны (чынында тору) буенча беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче медицина оешмасына һәм амбулатор шартларда паллиатив махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына җибәрелә.

Пациент чыгарылганнан соң ике эш көне дәвамында паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ пациент турында мәгълүмат алган медицина оешмасы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының № 345н, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 31 маендагы № 372н «Сәламәтлек саклау өлкәсендә үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы медицина оешмалары, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары һәм иҗтимагый берләшмәләр, башка коммерцияле булмаган оешмалар арасында үзара хезмәттәшлек тәртибен дә кертеп, паллиатив медицина

ярдәме күрсәтүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» боерыгы нигезендә пациентны беренчел тикшерүне һәм алга таба күзәтүне оештыра.

6. Медицина оешмалары тарафыннан («Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар Республика клиник хастаханәсе» ДАССУ, (Казан шәһ.);

«Кама балалар медицина үзәге» ДАССУ (Яр Чаллы шәһ.); «Перинаталь үзәкле Балалар шәһәр хастаханәсе» ДАССУ (Түбән Кама шәһ.); «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ) пациентка (пациентның законлы вәкиленә) махсус медицина җиһазлары һәм аңа кирәкле чыгым материалларын тапшыру пациент амбулатор шартларда паллиатив медицина ярдәме ала торган медицина оешмасының Россия Федерациясе гражданлык законнарына туры китереп төзелә торган килешү нигезендә пациентка (аның законлы вәкиленә) өй шартларында озакка сузылган ИВЛ үткәрү өчен кирәкле медицина эшләнмәләрен һәм җиһазларын тапшыру турында табиблык комиссиясе карары кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла (килешүнең тәкъдим ителә торган формасы әлеге боерыкның кушымта № 3тә китерелгән).

Медицина оешмасының күрсәтелгән затлары тарафыннан җиһазларны кире кайтару медицина җиһазларын кире кайтару акты буенча башкарыла.

Озакка сузылган респиратор ярдәменә мохтаҗ пациентка (аның законлы вәкиленә) ИВЛ аппаратын тапшырганда пациентның (аның законлы вәкиленең, туганнарының, пациентны караган башка затларның) 2-4 сәгать дәвамында үпкәләрнең көтелмәгән вентиляциясенә ярдәм итәргә сәләте булмаган очракта икенче ИВЛ аппараты тапшыру тәэмин ителә.

7. Алга таба өйдә ИВЛ өчен пациентны медицина оешмасыннан өйгә медицина транспортировкасы медицина оешмасының табибы-анестезиологы- реаниматологы озатуында «В» яки «С» класслы медицина транспортыннан файдаланып гамәлгә ашырыла. Гражданин яшәү урыны буенча ашыгыч медицина ярдәме станциясенең (медицина оешмасының ашыгыч медицина ярдәме бүлегенең) «В» яисә «С» класслы медицина транспортыннан файдалану рөхсәт ителә.

8. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыруда катнашучы, беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче медицина оешмаларының җитәкчеләре, пациентның ИВЛ алу өчен өй шартларына күчерелүе турында мәгълүмат алгач, өй шартларында ИВЛ алучы пациентны стационарга күчерүне таләп итә торган хәлләр барлыкка килгәндә чараларның исемлеген һәм эзлеклелеген медицина оешмасы буенча боерык тарафыннан билгеләп һәм күрсәтелгән чараларны үтәү өчен җаваплы затны билгеләп (алга таба - медицина оешмасының җаваплы заты).

9. Өй шартларында ИВЛда булган пациентка күзәтү тәэмин ителә:

паллиатив медицина ярдәменең күчмә патронаж хезмәте белгечләре тарафыннан (планлы күзәтү айга ике тапкырдан да ким түгел);

гражданинның яшәү урыны буенча медицина оешмасы боерыгы белән билгеләнгән табиб-анестезиолог-реаниматолог һәм медицина оешмасының җаваплы заты тарафыннан (планлы күзәтү айга бер тапкырдан да ким булмаска тиеш, клиник шартларга бәйле);

өйдә ИВЛ үткәрүгә әзерлекне гамәлгә ашыручы медицина оешмасының табибы-анестезиологы-реаниматологы тарафыннан (өч айга бер тапкырдан да ким булмаган планлы күзәтү)

Өйдә үпкәгә балаларга озакка
сузылган ясалма вентиляция ясау
чараларын оештыру тәртибенә
Кушымта №1

Тәкъдим ителгән форма

## Өйдә үпкәгә ясалма вентиляция ясауга хәбәр ителгән ирекле ризалык

Мин, ____________________________________________________________
(пациент фамилия-исеме )

«___»____________ елның туган, ________________________ Законлы вәкиле йөзендә ____________________________________________ нигезендә эш итүче,
(документ-нигез)

______________________________________________адресы буенча теркәлгән
өйдә үпкәгә ясалма вентиляция ясауны дәвам итү өчен медицина оешмасыннан (стационардан) күчерү мөмкинлеге белән таныштырылдым.

Өйдә үпкәләрнең ясалма вентиляциясен үткәрүне дәвам итү өчен мине медицина оешмасыннан (стационардан) күчерү өчен хәбәр ителгән ирекле ризалык бирәм.

Медицина хезмәткәре ___________________________________________________
(медицина хезмәткәре вазыйфасы, исем-фамилиясе)

тарафыннан минем өчен уңайлы формада өйдә үпкәләрнең ясалма вентиляциясе һәм медицина хезмәткәрләре, шул санда табиб анестезиолог-реаниматолог, тарафыннан күзәтү ни рәвешле тормышка ашырылуы турында аңлатылды, дип раслыйм.

Мин өзлегүләр үсешенең мөмкин куркынычы турында, шул санда үпкәләрнең ясалма вентиляциясе өчен медицина җиһазларын куллануга бәйле куркынычы турында, таныштырылдым.

Миңа өйдә үпкәләрнең ясалма вентиляциясен дәвам итү өчен яшәү урыны буенча медицина оешмасыннан күчерүдән баш тарту хокукым булуы аңлатылды.

Минем сәламәтлегемнең торышы яки мин законлы вәкиле булган затның торышы турында мәгълүмат тапшырылырга мөмкин булган мин сайлаган затлар турында мәгълүматлар (кирәкмәгәнне сызып ташларга):

______________________________________________________________________
(гражданин исем-фамилиясе, контакт телефоны)

Пациент (Законлы вәкил) __________/_____________________________/________
имза пациент (законлы вәкил) исем-фамилиясе дата

Медицина хезмәткәре ___________/______________/__________________________/_________
вазыйфа имза медицина хезмәткәре исем-фамилиясе дата

Өйдә үпкәгә балаларга озакка
сузылган ясалма вентиляция ясау
чараларын оештыру тәртибенә
Кушымта №2

Тәкъдим ителгән үрнәк

## Пациентның өй шартларының хәле турында
## Анкета

1. Пациентның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта)
_______________________________________________

2. Туу датасы, елы, туу урыны _______________________________

3. Яшәү урыны адресы (теркәлү урыны, чынында яшәү урыны)
_______________________________________________

4. Пациентның мәҗбүри медицина иминияте полисы номеры
_______________________________________________

5. Законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта)
_______________________________________________

6. Законлы вәкилнең туу датасы, елы, туу урыны ______________
_______________________________________________

7. Законлы вәкилнең яшәү урынының адресы (теркәү урыны, чынында яшәү урыны)_______________________________
_______________________________________________

8. Пациент яши торган торак бинаның төре:

☐ торак йорт ☐ торак йортның бер өлеше

☐ фатир ☐ фатирның бер өлеше

☐ бүлмә

9. Торак бинада стационар телефон булуы:
☐ әйе ☐ юк

10. Торак бинага кергәндә домофо булуы:
☐ әйе ☐ юк

11. Кичектергесез оператив хезмәт өчен торакның үтемлеге (йортка якын килү):
☐ әйе ☐ юк

12. Торак бинада энергетика ресурслары турында мәгълүмат:
12.1. Торак бинада электр белән тәэмин итү бар:
☐ әйе ☐ юк

Электр розеткалары җиргә тоташкан:
☐ әйе ☐ юк ☐ мәгълүмат юк

Өй шартларында медицина эшләнмәсен куллану өчен техник таләпләргә туры килә торган удлинительләр куллану мөмкин:
☐ әйе ☐ юк☐ мәгълүмат юк

Өй шартларында медицина эшләнмәсен куллану өчен электр челтәрендә көчәнеш җитәрлек:

☐ әйе ☐ юк ☐ мәгълүмат юк

12.2. Торак бинада су белән тәэмин итү булу:
☐ әйе ☐ юк
☐ үзәкләштерелгән су белән тәэмин итүсистемасы
☐ үзәкләштерелмәгән су белән тәэмин итүсистемасы
☐ кайнар су белән тәэмин итү ☐ салкын су белән тәэмин итү

12.3. Торак бинада үзәкләштерелгән су чыгару булу:
☐ әйе ☐ юк

12.4. Торак бинада җылыту системасы гыйбарәт:
☐ үзәкләштерелгән җылыту системасы
☐ үзәкләштерелмәгән җылыту системасы (күрсәтергә нинди)___________________________

13. Торак бинада пациентны янгын куркынычсызлыгы белән тәэмин итү турында мәгълүматлар:
Торак бинаның янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килүе:
☐ әйе ☐ юк

Торак бинада янгын сүндергечнең булуы:
☐ әйе ☐ юк

Янгын сүндергечнең төзек хәлдә булуы:
☐ әйе ☐ юк

Торак бинада аварияле чыгу юлының булуы
☐ әйе ☐ юк ☐ мәгълүмат юк

Торак бинада янгын булу очрагында гамәлләр планы булу
☐ әйе ☐ юк ☐ мәгълүмат юк

14. Торак бинада һаваны кондиционерлау һәм суыту системалары бар:
☐ әйе ☐ юк

Торак бинада һаваны кондиционерлау (суыту) системалары гыйбарәт:
☐ кондиционер ☐ сплит-система ☐ һаваны дымландыру системасы
☐ башка (күрсәтергә )________________________________________________________

15. Торак бинада техник яктан төзек суыткыч (суыткыч камера) булу:
☐ әйе ☐ юк

16. Ишекнең зурлыгы медицина эшләнмәсен тоткарлыксыз алып керергә мөмкинлек бирә:
☐ әйе ☐ нет

17. Медицина эшләнмәсен торак бинада урнаштыру очрагында аның янына тоткарлыксыз якын килүне тәэмин итү турында мәгълүматлар:
☐ әйе ☐ юк ☐ башка (күрсәтергә)______________________________________________

18. Торак бинада йорт хайваннары булу:
☐ әйе ☐ юк
Төре һәм саны (җавап «әйе» булса) ________________________________

19. Торак бинада бөҗәкләр һәм (яки) кимерүче хайваннар булу:

☐ әйе ☐ юк ☐ мәгълүматлар юк

Пациент _________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), имзасы)

Законлы вәкиле _________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), имзасы)
Дата ___________________

Өйдә үпкәгә балаларга озакка
сузылган ясалма вентиляция ясау
чараларын оештыру тәртибенә
Кушымта №3

Йорт шартларында озакка сузылган ИВЛда булган пациентны турыдан-туры карауны гамәлгә ашырачак затлар тарафыннан үзләштерелгән компетенцияләр
исемлеге

1. Трахеобронхиаль агач санациясе.
2. Назогастраль зонд кертү (алга таба - НГЗ), НГЗ аша ашату.
3. Гастростоманы алыштыру, гастростома артыннан карау, гастростома аша ашату буенча гамәли күнекмәләр.
4. Трахеостомик канюляны алыштыру, трахеостома артыннан карау буенча гамәли күнекмәләр.
5. Кул ярдәмендә ИВЛ үткәрүне белү.
6. ИВЛ аппаратын көйләү, эксплуатацияләү, төзеклеген тикшерү, агымдагы кимчелекләрен бетерү буенча күнекмәләр.
7. Пациент хәленең параметрлары: сулыш ешлыгы, пульс ешлыгы, тире капламының төсләре, күкрәк читлеге экскурсияләре, тирләве, йокычанлыгы, тән температурасы нигезендә ИВЛ адекватлыгын бәяләү.
8. ИВЛ параметрларын: ИВЛ аппараты контурында агымны; мәҗбүри сулыш алуларның ешлыгын; сулыш алуның иң югары басымнарын; сулыш чыгару ахырында уңай басымны; сулыш алуның күләмнәрен; пульслы оксиметр тикшерү астында кислород концентрациясен; дымландыргычның температурасын урнаштыра белү яки җылылык-дымлылык саклаучы фильтрны урнаштыра һәм алыштыра белү.
9. Кризислы кичектергесез хәлләргә: электр белән тәэмин итүнең өзеклегенә; очраклы деканюляциягә; трахеостомик канюлянең обтурациясенә; ИВЛ аппараты ватылуга; пациентның хәле начарлануга адекват реакция ясау.
10. Йогышлардан иминлекне тәэмин итү буенча гигиена процедураларын һәм чараларны үтәү.
11. Түбәндәге ярдәмчел җиһазлардан файдалана белү: кислород концентраторы, электроаспиратор, пульсоксиметр, йөткерттерү аппараты, дымландыргыч.
12. Чыгым материалларын куллану кагыйдәләрен белү (алыштыруның ешлыгы, утильләштерү кагыйдәләре, минималь рөхсәт ителгән калган материал).
13. Өлкәннәр өчен алгоритм буенча йөрәк-үпкә реанимациясе буенча чараларның төп комплексын башкара алу.

Пациент (Законлы вәкиле)

___________________________________ ___________ _____________

фамилия-исеме имза дата

Пациентны турыдан-туры карауны гамәлгә ашырачак затлар:

_________________________________________ _____________ _______________

фамилия-исеме имза дата

_________________________________________ _____________ _______________

фамилия-исеме имза дата

Йорт шартларында озакка сузылган ИВЛда булган гражданинны карау буенча укыту үткәргән табиб-анестезиолог-реаниматолог:

_________________________________________ _____________ _______________

фамилия, исеме, атасының исеме тулысынча имза дата

22.04.2021_ № _765
ТР Сәламәтлек саклау
Министрлыгы боерыгына
Кушымта №3

Тәкъдим ителгән форма

Медицина җиһазларын өйдә түләүсез вакытлы файдалануга тапшыру турында
Килешү

__________________________ «______» _______________ 20___г.
төзү урыны

Бер яктан, устав нигезендә гамәлдә булучы, алга таба “Медицина оешмасы” дип аталучы,
_____________________________________________________________________________,
медицина оешмасы атамасы

баш табиб йөзендә
_____________________________________________________________________________,
баш табиб фамилиясе, исеме, атасының исеме

һәм икенче яктан алга таба “Гражданин” дип аталучы ________________________
пациент фамилия-исеме

_____________________________________________________________________________
(законлы вәкилнең гамәлләрен нигезләүче документның атамасы, реквизитлары)

бергә «Яклар» дип аталучы, түбәндәге турында әлеге килешүне төзеделәр (алга таба Килешү):

**1. Килешү Предметы. Төп нигезләмәләр**

1.1. Килешүнең предметы булып, махсус медицина җиһазын куллану белән Пациентка_____________________________________________________________
(фамилия, исеме, атасының исеме, туу датасы )

адресы буенча яшәүче ________________________________________________________
өйдә паллиатив медицина ярдәме күрсәтү буенча Якларның үзара хезмәттәшлеге тора

1.2. Әлеге Килешүнең № 1 Кушымтасында күрсәтелгән махсус медицина җиһазын һәм аның белән файдалану өчен кирәк булган медицина билгеләнешендәге предметларны (алга таба - Җиһаз) Медицина оешмасы бирә, ә Гражданин түләүсез вакытлыча куллануга кабул итә һәм Җиһазны, нормаль тузуны исәпкә алып, кабул иткәндәге халәтендә кире кайтаруга вәгъдә бирә.

1.3. Әлеге Килешү буенча тапшырыла торган Җиһаз Медицина оешмасы карамагында тора.

1.4. Килешү буенча Җиһазлардан түләүсез вакытлыча файдалану срогы _____________________________________________________________________

1.5. Җиһаз Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән адрес буенча гына кулланыла.

1.6. Җиһаз Медицина оешмасы тарафыннан Гражданинга әлеге Килешүгә кул куелган көннән 2 (ике) эш көне эчендә Җиһазга кагыла торган барлык техник паспортларның, файдалану буенча инструкция күчермәләре белән Җиһазны Кабул итү-тапшыру акты (әлеге Килешүгә кушымта №2) буенча тапшырыла.

1.7. Җиһазны Кабул итү-тапшыру актына Яклар тарафыннан кул кую вакытыннан башлап Җиһазның ватылу яки аңа зыян килү куркынычы Гражданинга күчә.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Медицина оешмасы:

2.1.1. Гражданинга Җиһазны түләүсез вакытлыча файдалануга тапшырганчы аның Җиһаз белән куллану кагыйдәләренә өйрәтүне тәэмин итә.

2.1.2. Кабул итү-тапшыру акты буенча комплектлы итеп Җиһазны төзек хәлдә тапшыра.

2.1.3. Җиһазны Кабул итү-тапшыру актына Яклар тарафыннан кул кую вакытыннан башлап 1 көн эчендә Җиһазның эшләтеп җибәрү-көйләү эшләрен башкара.

2.1.4. Җиһаздан куллануны контрольдә тота.

Җиһазны нәтиҗәсез яки максатсыз файдалану ачыкланган очракта, Медицина оешмасы Гражданинга язма рәвештә кисәтү җибәрә.

Җиһазны нәтиҗәсез яки максатсыз файдалану буенча кабат ачыкланган очракта, Гражданинга Килешүне вакытыннан алда өзү һәм Җиһазны кире кайтару турында язма белдерү кәгазе җибәрелә.

2.1.5. Гражданин тарафыннан Җиһазны кайтарганда Медицина оешмасы Гражданин катнашында Җиһазга техник карап тикшерү, аның комплектлылыгын тикшерү үткәрә, бу хакта Җиһазны Кире кайтару акты төзелә (әлеге Килешүгә № 3 кушымта).

2.1.6. Медицина оешмасы җитештерүче тарафыннан билгеләнгән срокларда Җиһазга сервис хезмәте күрсәтә, шулай ук Гражданин запросы буенча Җиһазның халәтен тикшерә.

2.2. Гражданин:

2.2.1. Медицина оешмасының вәкаләтле хезмәткәрләренә Җиһазның халәте, аның максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын контрольдә тоту кагыйдәләренә (алга таба - Кагыйдәләр) туры китереп, Җиһазны урнаштыру, җибәрү-көйләү эшләрен үткәрү, сервис хезмәте күрсәтү, Җиһазның халәтен тикшерү өчен, шулай ук, Җиһазны куллануны контрольдә тоту өчен бинага тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итә (әлеге Килешүгә №4 кушымта).

2.2.2. Җиһазны залогка бирергә, Җиһазны өченче затларга, шул исәптән арендага, бушлай файдалануга тапшырырга хокуклы түгел.

2.2.3. Әлеге Килешү буенча үз хокукларын һәм бурычларын өченче затларга тапшырырга хокуклы түгел.

2.2.4. Куллану срогы чыкканчы Җиһазны Медицина оешмасына Җиһазны кире кайтару акты буенча кире кайтарырга хокуклы (Килешүнең 1.4 пункты).

Җиһазны вакытыннан алда кайтару турында Медицина оешмасына Җиһазны кире кайтару турында язмача белдерү кәгазе җибәрелә.

2.2.5. Җиһаздан бары тик аның билгеләнеше буенча һәм әлеге Килешү шартлары нигезендә генә файдалануны тәэмин итә.

2.2.6. Медицина оешмасының язмача рөхсәтеннән башка Җиһазның аергысыз яхшыртуын башкарырга хокуклы түгел.

2.2.7. Җиһазның төзек хәлдә булуын тәэмин итә.

Җиһазның эшендә техник проблемалар туганда Гражданин бу хакта Медицина оешмасы хезмәткәрләренә хәбәр итәргә тиеш.

2.2.8. Җиһазны Медицина оешмасына Җиһазны Кире кайтару акты буенча тиешле халәттә, төзек хәлдә, комплектлы итеп кайтарырга бурычлы.

2.2.9. Әлеге Килешүгә карата булган барлык үзгәрешләр (мәсәлән, үзенең яшәү урыны, пациентның яшәү урыны, паспорт белешмәләре һәм башкалар) турында Медицина оешмасына үзгәрешләр кертелгәннән соң өч көн эчендә язмача рәвештә хәбәр итәргә бурычлы.

## 3. Конфиденциальлек

3.1. Килешү буенча һәр якның эшчәнлеге турында һәм Килешү буенча алар белән бәйле теләсә кайсы башка затның эшчәнлеге турында мәгълүмат конфиденциаль булып тора.

## 4. Якларның җаваплылыгы

4.1. Әлеге Килешү буенча бурычларны үтәмәгән өчен Яклар Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән билгеләнгән җаваплылыкны тоталар.

4.2. Яклар әлеге Килешү буенча бурычларны өлешчә яки тулысынча үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителәләр, әгәр бу хәл әлеге Килешү төзегәннән соң яклар алдан күрә алмый яисә булдырмый кала алмаган гадәттән тыш характердагы хәлләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән үтә алмаслык көчтәге хәлләр барлыкка килү сәбәпле килеп чыккан булса.

4.3. Әлеге Килешү тексты буенча хәл ителеше булмаган мәсьәләләр буенча Яклар арасында килеп чыгарга мөмкин булган бәхәсләр һәм каршылыклар гамәлдәге законнар нигезендә сөйләшүләр юлы белән хәл ителәчәк.

4.4. Бәхәсле мәсьәләләр сөйләшүләр барышында җайга салынмаган очракта, бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Әлеге Килешү аңа кул куелган вакыттан башлап үз көченә керә һәм Килешү буенча Яклар тарафыннан үз бурычларын тулысынча үтәп чыгуга кадәр гамәлдә була.

5.2. Килешү Якларның язма килешүе буенча үзгәртелергә яки өзелергә мөмкин.

5.3. Медицина оешмасы Җиһаздан файдалану срогы чыкканчы Килешүне өзүне таләп итәргә хокуклы (Килешүнең 1.4 пункты) түбәндәге очракларда:
1) Килешү шартларын бозып Җиһаздан файдалану очрагында яки аның билгеләнеше буенча файдаланмаса;
2) Җиһазга зыян китерелсә;
3) Җиһазны эксплуатацияләү инструкциясен һәм Кагыйдәләрен бозып Җиһаздан файдалану очрагында;
4) Әлеге Килешүне төзү өчен нигез булган шартлар үзгәргән яисә Килешү буенча Гражданин тарафыннан кабул ителгән йөкләмәләрнең үтәлмәгәне очрагында.
5.4. Барлык белдерүләр һәм хәбәрләр язма рәвештә җибәрелергә тиешләр.
5.5. Әлеге Килешүдә каралмаган башка мәсьәләләр буенча Яклар гамәлдәге законнарга таянып эш итәләр.
5.6. Кушымталар:
Кушымта № 1. Өйдә медицина җиһазыннан файдалану өчен кирәкле булган медицина җиһазының, аның әсбәпларының, медицина билгеләнешендәге предметларның исемлеге;
Кушымта № 2. Җиһазлар кабул итү һәм тапшыру акты;
Кушымта № 3. Җиһазларны кире кайтару акты;
Кушымта № 4. Җиһазларның торышын, нәтиҗәле һәм максатчан кулланылышын контрольдә тоту кагыйдәләре.

**6. Якларның реквизитлары һәм имзалары**

Медицина оешмасы________________________________________________
атамасы
Юридик адресы:____________________________________________________
ИНН _____________________
Баш табиб _______________/____________________
имза имза расшифровкасы

М.П.

Гражданин
________________________________________________________________________
фамилия, инициаллар
Паспорт:________________ бирү датасы:_______________________________________
Бирү органы: ________________________________________________________
Яшәү һәм теркәлү урыны:______________________________________
__________________________________ Контакт телефон: ____________________

Имза:________________ Дата: ___________________

_______________ 20 ___ ел.   № _____
Медицина җиһазларын өйдә түләүсез
вакытлы файдалануга тапшыру
килешүенә
Кушымта № 1

Өйдә файдалану өчен кирәкле медицина җиһазының, аның әсбәпларының, медицина билгеләнешендәге предметларның исемлеге

1.
2.
3.

Яклар имзалары

Медицина оешмасы___________________________________________________
атамасы

Баш табиб____________________/______________________________________________
имза                    имза расшифровкасы (фамилия, инициаллары)

М.П.

Гражданин____________________/________________________________________________
имза                          имза расшифровкасы (фамилия, инициаллары)

_______________ 20 ___ ел.   № _____
Медицина җиһазларын өйдә түләүсез вакытлы файдалануга тапшыру килешүенә
Кушымта № 2

## Җиһазны кабул итү-тапшыру акты

_____________________ «______» _____________ 20___ел.
төзү урыны

Бер яктан, устав нигезендә гамәлдә булучы, алга таба «Медицинская оешмасы» дип аталучы__________________________________________________________________,
Медицина оешмасы атамасы

баш табиб йөзендә_________________________________________________________________,
баш табиб фамилиясе, исеме, атасының исеме

һәм икенче яктан алга таба «Гражданин» дип аталучы ___________________________________
пациентның (законлы вәкилнен) фамилия-исеме

_________________________________________________________________________________

бергә «Яклар» дип аталучы, түбәндәге турында әлеге актны төзеделәр (алга таба - Акт):

1. Әлеге Акт буенча Медицина оешмасы Гражданинга тапшыра, ә Граждан файдалану өчен кирәкле түбәндәге җиһазны, аңа әсбәпларны, медицина билгеләнешендәге предметларны (алга таба - Җиһаз) кабул итә:

| № п/п | Атамасы | Инвентарь номеры | Серия номеры | Саны | Бәясе, сум. |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |
| 4. | | | | | |
| Итого: | | | | | |

Җиһазны кабул итү-тапшыру акты буенча Җиһазга бәйләнеше булган бөтен техник паспортларның, эксплуатация буенча инструкциянең күчермәләре беләнңң.

2. Әлеге Актның 1 пунктында күрсәтелгән Җиһаз комплектланган һәм төзек хәлдә. Якларның бер-берсенә карата дәгъвалары юк.

3. Әлеге Акт 2 (ике) нөсхәдә төзелгән, аның берсе Медицина оешмасы өчен, икенчесе - Гражданин өчен.

Якларның имзалары

Медицина оешмасы ______________________________________________________
атамасы

Баш табиб______________________/_____________________________________________
имза   имза  расшифровкасы (фамилия, инициаллар)

М.П.

Гражданин___________________/_____________________________________________
имза   имза расшифровкасы (фамилия, инициаллар)

_______________ 20 ___ ел. № ______
Медицина җиһазларын өйдә түләүсез вакытлы файдалануга тапшыру килешүенә
Кушымта № 3

Җиһазны кире кайтару
Акты

_____________________ «______» ______________ 20___г.
төзү урыны

Бер яктан, устав нигезендә гамәлдә булучы, алга таба «Медицинская оешмасы» дип аталучы_____________________________________________________________________,
Медицина оешмасы атамасы
баш табиб йөзендә______________________________________________________________,
баш табиб фамилиясе, исеме, атасының исеме
һәм икенче яктан алга таба «Гражданин» дип аталучы ___________________________________
пациентның (законлы вәкилнең) фамилия-исеме
_____________________________________________________________________________

бергә «Яклар» дип аталучы, түбәндәге турында әлеге актны төзеделәр (алга таба - Акт):

1. Әлеге Акт буенча Медицина оешмасы Гражданинга тапшыра, ә Граждан файдалану өчен кирәкле түбәндәге җиһазны, аңа әсбәпларны, медицина билгеләнешендәге предметларны (алга таба - Җиһаз) кабул итә:

| № п/п | Атамасы | Инвентарь номеры | Серия номер | Саны | Бәясе, сум. |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |
| 4. | | | | | |
| Итого: | | | | | |

Җиһазны кабул итү-тапшыру акты буенча Җиһазга бәйләнеше булган бөтен техник паспортларның, эксплуатация буенча инструкциянең күчермәләре белән.

2. Әлеге Актның 1 пунктында күрсәтелгән Җиһаз комплектланган һәм төзек хәлдә. Якларның бер-берсенә карата дәгъвалары юк.

3. Әлеге Акт 2 (ике) нөсхәдә төзелгән, аның берсе Медицина оешмасы өчен, икенчесе - Гражданин өчен.

Якларның имзалары

Медицина оешмасы______________________________________________________________
атамасы

Баш табиб _________________/__________________________________________________
имза имза расшифровкасы (фамилия, инициаллар)

М.П.

Гражданин __________________/____________________________________________________
имза имза расшифровкасы (фамилия, инициаллар)

_______________ 20 ___ ел. № ______

Медицина җиһазларын өйдә түләүсез вакытлы файдалануга тапшыру килешүенә
Кушымта № 4

## Җиһазның торышын, нәтиҗәле һәм максатчан кулланылышын тикшерү кагыйдәләре

1. Медицина оешмасы Җиһазның комплектлыгын һәм төзеклеген даими тикшереп тору хокукын үзендә калдыра.
2. Комплектлыкны һәм төзеклекне тикшерү пациент (законлы вәкил) барында Медицина оешмасының вәкаләтле вәкилләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.
3. Тикшерү көне турында пациент (законлы вәкил) алдан ук кисәтелә, ләкин тикшерү көненә кадәр ике тәүлектән дә соңга калмыйча.
4. Җиһазның төзек булмавы ачыкланган очракта пациент (законлы вәкил) бу хакта Медицина оешмасын кичекмәстән кисәтергә тиеш. Каршы очракта бәхәс барлыкка килгәндә алар әлеге хәлләргә сылтама ясарга хокуклы түгел.
5. Медицина оешмасының вәкаләтле вәкиле, җиһазның төзек булмавын һәм (яки) комплектлы булмавын ачыклаган очракта, ачыкланган җитешсезлекләрне күрсәтеп, ике яклы акт төзи. Югарыда телгә алынган акт, бер яктан, Медицина оешмасының вәкаләтле вәкиле, икенче яктан, пациент (законлы вәкил) тарафыннан имзалана.

Яклар имзалары

Медицина оешмасы______________________________________________________
атамасы

Баш табиб____________________/____________________________________________
имза имза расшифровкасы (фамилия, инициаллар)

М.П.

Гражданин____________________/____________________________________________
имза имза расшифровкасы (фамилия, инициаллар)